ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЫБНО-СЛОБОДСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛЫК БИСТӘСЕ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2021 Балык Бистәсе штп. № 290пи

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтен тапшыру турында дини оешмаларның гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия турында Нигезләмәне раслау турында

«Дәүләт һәм муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру турында» 2010 елның 30 ноябрендәге 327-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Уставы нигезендә КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтен тапшыру турында дини оешмаларның гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия турында Нигезләмәне расларга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасары А.К. Вафинага йөкләргә.

Җитәкче Р.Л. Исланов

Татарстан Республикасы Балык_Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 29 декабрендәге 290пи номерлы карары белән расланган.

# Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтен тапшыру турында дини оешмаларның гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия турында НИГЕЗЛӘМӘ

## 1. Гомуми нигезләмә

1.1 Әлеге НигезләмәТатарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтен тапшыру турында дини оешмаларның гаризаларын караганда барлыкка килә торган мәсьәләләр буенча комиссия (алга таба- комиссия) эшчәнлегенең тәртибен билгели.

1.2 Комиссия үз эшчәнлегендә Россия Федерациясе е Конституциясенә, федераль законнарга, Россия Федерациясе Президенты Указларына һәм күрсәтмәләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәте карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Президенты Указларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарларына һәм күрсәтмәләренә, Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының муниципаль норматив-хокукый актларына, шулай ук әлеге Нигезләмәгә таяна.

1.3 Комиссия тарафыннан аның компетенциясе нигезендә кабул ителгән карарлар вәкаләтле орган тарафыннан Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру турында карарлар кабул итү өчен нигез булып тора.

Вәкаләтле орган – Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты.

## 2. Комиссиянең төп бурычлары

2.1 1 Комиссиянең төп бурычларына түбәндәгеләр керә:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль милектә булган дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турындагы дини оешмаларның гаризаларын караганда барлыкка килгән каршылыкларны җайга салу;

дини оешмага дини билгеләнештәге мөлкәтне тапшыру турында карар кабул итүгә бәйле рәвештә аларның хокуклары һәм (яки) законлы мәнфәгатьләре бозылуы яисә дини оешма гаризасын карау белән бәйле вәкаләтле органның гамәлләре (гамәл кылмаулары) турында физик һәм юридик затларның гаризаларын карау.

## 3. Комиссиянең төп функцияләре

3.1 Комиссия үзенә йөкләнгән бурычлар нигезендә түбәндәге функцияләрне башкара:

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнарыннан һәм оешмалардан үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен кирәкле мәгълүмат соратып ала;

үз утырышларында комиссия компетенциясенә керә торган мәсьәләләр буенча Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары, дини белем, культурология, хокук һәм башка өлкәләрдәге оешма вәкилләрен һәм белгечләрен тыңлый;

комиссия эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары, дини белем, культурология, хокук һәм башка өлкә белгечләрен һәм оешмаларны җәлеп итә;

Комиссия компетенциясенә керүче мәсьәләләрне карау өчен эшче төркемнәр оештыра;

вәкаләтле органга үз компетенциясе чикләрендәТатарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы территориясендә муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру яки  тапшырудан баш тарту турында тәкъдим белән нигезле карар кабул итә.

## 4. Комиссиянең хокуклары

4.1 Комиссия түбәндәге хокукларга ия:

комиссия эшендә катнашу өчен Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы җирле үзидарә органнары, дини белем, культурология, хокук һәм башка өлкәләрдә белгечләрне һәм оешмаларны җәлеп итәргә;

Комиссия компетенциясенә керүче мәсьәләләрне карау өчен эшче төркемнәр оештырырга.

## 5. Комиссия эшчәнлеге тәртибе

5.1 Комиссия составы Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты карары белән раслана.

5.2 Комиссия составына комиссия рәисе, комиссия рәисе урынбасары, комиссия секретаре һәм комиссиянең башка әгъзалары керә.

5.3 Комиссия эшчәнлеге белән җитәкчелек итүне комиссия рәисе башкара.

5.4 Комиссия утырышлары әлеге Нигезләмә нигезендә хәл итүне таләп итә торган мәсьәләләр килеп чыккан саен үткәрелә.

Комиссия рәисе карары буенча комиссиянең күчмә утырышлары үткәрелергә мөмкин.

5.5 Комиссия утырышларын чакыру, үткәрү һәм ул кабул иткән карарларның үтәлешен контрольдә тоту комиссия рәисенә йөкләнә.

Комиссия утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының яртысыннан артыгы катнашса, хокуклы дип санала. Комиссия әгъзасы, утырышта ул булмаганда, карала торган мәсьәләләр буенча үз фикерләрен язма рәвештә бирергә хокуклы.

5.6 комиссия карары утырышта катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә һәм утырыш беркетмәсе белән рәсмиләштерелә, аңа аның рәисе һәм комиссия секретаре кул куя.

Комиссия әгъзаларының тавышлары тигез булганда, комиссия рәисе тавышы хәлиткеч булып тора.

Комиссия әгъзаларының кабул ителгән карар белән килешмәгән аерым фикере комиссия карарына кушымта рәвешендә рәсмиләштерелә.

5.7 Комиссия тарафыннан аның компетенциясе нигезендә кабул ителгән карарлар вәкаләтле органнар тарафыннан муниципаль милектәге дини билгеләнештәге мөлкәтне дини оешмаларга тапшыру турында карарлар кабул итүгә нигез булып тора.

5.8 Комиссия карары, шулай ук әлеге карар белән килешмәгән комиссия әгъзаларының аерым фикере, Интернет челтәрендә http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру өчен вәкаләтле органга 7 көн дәвамында җибәрелә.